РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

20 декабрь 2023 ел №31

Ядегәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ядегәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Ядегәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 7 ноябрендәге 30 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 9 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 16 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 24 номерлы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Ядегәр авыл җирлеге башлыгына классы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә hhth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә hhth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы А.Н.Фәйзуллин